**СОВЕТ КУРКАЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д. разъезда Куркачи, ул. Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422730 Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык тимер юл разъезды пос, Гагарин ур., 7

Тел./факс: +7(84365) 71-2-15, e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18 август 2022 ел** **№ 48**

**Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлегенең норматив хокукый актларын хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:
«Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге советы кабул иткән «Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлегенең мактаулы гражданы» дигән мактаулы исем бирү турында» 2008 елның 18 11 декабрендәге 154 номерлы карар;
- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге советы кабул иткән «Гражданнарның беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын, шул исәптән янгын куркынычсызлыгы эшчәнлеген тәэмин итүдә катнашу рәвешләрен билгеләү турында» Нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 24 сентябрендәге 217 номерлы карар;
- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге советы кабул иткән «Авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңадан әзерләүгә, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ турында» 2010 елның 31 августындагы 270 номерлы карар.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет председателе,
Коркачык авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Салихҗанов